МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**15.08.2018** Казан ш. № 399

«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирү өчен «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә аның гарызнамәсе нигезендә урынга чыгып хезмәтләр күрсәтү буенча нигезләмә раслау турында

«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Учреждение) бүлекләрендә һәм филиалларында түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итү максатларында боерык бирәм:

1. Түбәндәге кушымталарны расларга:

«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен;

«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирү өчен

«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә аның гарызнамәсе нигезендә урынга чыгып хезмәтләр күрсәтү буенча нигезләмә.

2. Учреждение директоры Л.А.Мозаффаровага түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Учреждениедә күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр исемлеген раслауны;

түләүле хезмәтләр күрсәткән көчен түләү күләмен килештерүне һәм раслауны;

Учреждение бүлекләрендә һәм филиалларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Учреждение сайтында Учреждениедә түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат урнаштыруны.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары А.Д.Шәмсиевка йөкләргә.

**Министр в.б. – беренче урынбасар,**
**Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү**
**департаменты директоры** **Р.Р. Сибгатуллин**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 15.08.2018
№ 399 боерыгы белән расланды

**«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Учреждение) тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүнең әлеге тәртибендә (алга таба – Тәртип) Учреждение бүлекләре һәм филиаллары тарафыннан физик һәм юридик затларга түләүле хезмәтләр күрсәтү механизмы һәм шартлары, шулай ук мондый хезмәтләрне күрсәткән өчен Түләү билгеләү тәртибе билгеләнә.

1.2. Тәртип Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Бюджет колексы, «Россия Федерациясендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар һәм юридик затлар өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы карамагында торган дәүләт бюджет учреждениеләренең төп эшчәнлек төрләренә карый торган хезмәтләрне күрсәткән (эшләрне башкарган) өчен түләү билгеләүнең үрнәк тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы карары, Учреждение Уставы нигезендә эшләнде.

1.3. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр:

түләүле хезмәт – түләүле хезмәтләрнең билгеләнгән исемлеге нигезендә түләүле нигездә Учреждение бүлекләре һәм филиаллары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт;

заказчы – түләүле хезмәт артыннан мөрәҗәгать иткән, шәхсән яки тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән, үзенең вәкаләтләрен раслый торган документ нигезендә эш йөртүче вәкаләтле вәкиле аша гамәл кылучы физик зат яки юридик зат;

башкаручы – тиешенчә бүлек яки филиал турында Нигезләмә нигезендә гамәл кылучы Учреждение бүлеге яки филиалы;

документлар төзү буенча хезмәт – текст җыю, гариза тутыру, шартнамә яки декларация төзү буенча Учреждение белгечләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт;

урынга чыгып хезмәт күрсәтү – заказчы гаризасы нигезендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү һәм тиешле язу/исемлек теркәп, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү урынына документларны китерү максатында Учреждение белгеченең аның янына баруы һәм (яки) тиешле язу/исемлек төзеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән документларны китерү максатында Учреждение белгеченең заказчы гарызнамәсе буенча аның янына баруы.

1.4. Түләүле хезмәтләр исемлеге, шулай ук аларны күрсәткән өчен түләү күләме Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп, Учреждение борыгы нигезендә раслана.

1.5. Түләүле хезмәт күрсәтү башкаручының төп эшчәнлегенә зыян салырга яки аның сыйфатын начарайтырга тиеш түгел.

1.6. Учреждение бүлегендә яки филиалында Учреждение директоры боерыгы нигезендә бүлек яки филиал буенча тулаем алганда түләүле хезмәт күрсәтүне оештыру өчен җаваплы вазыйфаи зат билгеләнә, ул түләүле хезмәт күрсәтүне тәэмин итүче, түләүле хезмәт күрсәткән өчен түләнгән акчаларның счетка күчүен тикшерүдә тотучы вазыйфаи затлар исемлеген билгели.

1.7. Түләүле хезмәт күрсәткән өчен кирәкле документлар исемлеге:

хезмәткә түләгәнлекне раслый торган документ;

түләүле хезмәт күрсәтүгә шартнамә (документлар төзү һәм урынга чыгып хезмәт күрсәтү хезмәтләре өчен).

Документлар төзү буенча хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәнең үрнәк формасы әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада күрсәтелде.

Урынга чыгып хезмәт күрсәтүгә Хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк формасы әлеге боерык белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирү өчен «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчегә аның гарызнамәсе нигезендә урынга чыгып хезмәтләр күрсәтү буенча нигезләмәгә 1 нче кушымтада күрсәтелде.

Шартнамәнең төп нөсхәсе Учреждениенең финанс-икътисадый бүлегендә законнарда билгеләнгән срок дәвамында сакланырга тиеш.

## 2. ТҮЛӘҮЛЕ ХЕЗМӘТ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ ҖИТКЕРҮ

2.1. Учреждение бүлекләре һәм филиаллары тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр турында мәгълүмат түбәндәгечә урнаштырыла:

- Учреждение бүлекләрендә һәм филиалларында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү урыннарында мәгълүмат стендларында;
- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Учреждение сайтында (Порталында) (https://mfc16.tatarstan.ru).

2.2. Түләүле хезмәтләр күрсәтү турында мәгълүматта түбәндәгеләр була:

түләүле хезмәтләрне күрсәтү шартлары (шул исәптән түләүле хезмәтләрне күрсәтүгә түләү күләме һәм аларның графигы, урынга чыгып хезмәт күрсәтелә торган территорияләрнең графигы һәм исемлеге);

түләүле хезмәтләр исемлеге (шул исәптән урынга чыгып хезмәт күрсәткәндә күрсәтелә торган дәүләти, муниципаль һәм бүтән хезмәтләр);

урынга чыгып хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк рәвеше;

документлар төзү буенча хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк рәвеше;

түләү күчерү өчен банк реквизитлары, хезмәтләргә түләү өчен банктан түләү йөкләмәсе (квитанция) һәм аны тутыру үрнәге;

түләүле хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен җаваплы затларның элемтә өчен телефон номерлары, фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (соңгысы булган очракта);

Хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә корреспонденция кабул итү адреслары (шул исәптән телефон номеры һәм электрон почта адреслары).

## 3. УЧРЕЖДЕНИЕ БҮЛЕГЕНДӘ ЯКИ ФИЛИАЛЫНДА ТҮЛӘҮЛЕ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Документлар төзү буенча хезмәт хезмәт күрсәткән өчен түләгәннән соң мөрәҗәгать иткән көнне күрсәтелә.

3.2. Урынга чыгып хезмәт күрсәтү хезмәтләр күрсәткән өчен түләгәннән соң, шартнамәдә билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

3.3. Бүтән төрле түләүле хезмәтләр (күчермәләр ясау, скан аша чыгарту, документларны бастырып алу, текст җыю) заказчыга хезмәт өчен түләнгәннән соң, заказчы мөрәҗәгать иткән вакытта күрсәтелә.

3.4. Документлар төзү буенча хезмәт күрсәтү яки урынга чыгып хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча Күрсәтелгән хезмәтләр турында акт төзелә.

Күрсәтелгән хезмәтләр турында актның үрнәк формасы Документлар төзү буенча түләүле хезмәт күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк формасына кушымтада китерелде.

Урынга чыгып күрсәтелгән хезмәтләр турында актның үрнәк формасы Урынга чыгып түләүле хезмәт күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк формасына кушымтада күрсәтелде.

## 4. ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТКӘН ӨЧЕН ТҮЛӘҮ БИЛГЕЛӘҮ ТӘРТИБЕ

4.1. Түләүле хезмәтләрнең бәяләрен (тарифларын) исәпләү һәм раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар һәм юридик затлар өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы карамагында торган дәүләт бюджет учреждениеләренең төп эшчәнлек төрләренә карый торган хезмәтләрне күрсәткән (эшләрне башкарган) өчен түләү билгеләүнең үрнәк тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Учреждение түләүле хезмәтләргә бәяләрне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп раслый.

## 5. ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ҺӘМ ТҮЛӘНГӘННЕ КАЙТАРЫП АЛУ ТӘРТИБЕ

5.1. Түләүле хезмәт күрсәткән өчен түләү түләүле хезмәтне күрсәтер алдыннан заказчы тарафыннан налсыз яки акчалата исәп-хисап ясау юлы белән гамәлгә ашырыла.

5.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәренең мөрәҗәгать итүче янына барганы өчен түләү исәпләү тәртибе һәм Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәренең мөрәҗәгать итүче янына аның гарызнамәсе нигезендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирүен оештыру түләүсез гамәлгә ашырыла торган Гражданнар категорияләре исемлеген билгеләү турында» 2017 елның 07 декабрендәге 945 номерлы карары белән билгеләнгән исемлектәге затлар категорияләре өчен урынга чыгып хезмәт күрсәтү раслаучы документларны күрсәткән очракта түләүсез гамәлгә ашырыла.

5.3. Түләүле хезмәтләр күрсәткән өчен заказчылардан түләү счетына алынган акчалар Учреждениенең шәхси счетына күчә.

5.4. Түләнгәнне кайтарып алу заказчы гаризасы нигезендә түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

- заказчы тарафыннан акча артык түләнгән очракта;
- башкаручы гаебе белән түләүле хезмәт күрсәтелмәгәндә;
- күрсәтелә башлаганчы ук заказчы хезмәттән баш тартканда.

Түләүне кайтарып бирү заказчының түләүне кайтару турында гаризасы нигезендә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 6. ТҮЛӘҮЛЕ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮДӘН АЛЫНГАН АКЧАЛАРНЫ ТОТУ

6.1. Түләүле хезмәт күрсәтүдән алынган акчаларны тоту Учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге буенча расланган планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 7. ТҮЛӘҮЛЕ ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТҮ БУЕНЧА ХИСАПЛЫЛЫК

7.1. Түләүле хезмәтләр күрсәтү турында хисап Учреждение бүлекләре һәм филиаллары тарафыннан хисап аеннан соң килгән айның 1 нче көненә кадәрле срокта ай саен әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада китерелгән хисап формасы нигезендә тапшырыла.

7.2. Учреждение бүлекләрендәге һәм филиалларындагы хезмәткәрләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү барышында җибәрелгән бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар законнар нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының _______ № _____ боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 1 нче кушымта

**Үрнәк формасы**

**Документлар төзү буенча хезмәтләр күрсәтү турында**
**№ ____ шартнамә**

________________ ш. «____»__________ 20____ел.

«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе, __________ исеменнән, Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе филиалы турында нигезләмә, «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе Уставы нигезендә эш йөртүче, бер яктан һәм__________________________________________________________________________________ _________________________________________________________________________исеменнән, _____ ____________________________________________ нигезендә эш итүче, алга таба «Заказчы» дип атала, икенче яктан, алга таба – Яклар дип аталалар, әлеге Шартнамәне төзеде, түбәндәгеләр хакында:

## 1. ШАРТНАМӘНЕҢ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Заказчы тапшыра һәм түләү йөкләмәсен ала, ә Башкаручы түбәндәгеләрне төзү буенча хезмәт күрсәтү йөкләмәсен үз өстенә ала__________________________________________________
__________________________________________________________________________________
(түләүле хезмәтләрнең билгеләнгән исемлеге нигезендә документ аталышы)

1.2. Үтәлү территориясе –________________________________________________________.
(хезмәтләрне үтәүнең тиешле территориясе күрсәтелә)

Әлеге Шартнамә максатлары өчен үтәлү территориясе дигәндә аның чикләрендә Башкаручы әлеге Шартнамә буенча үзенең вазыйфаларын башкару йөкләмәсен алган территория аңлашыла.
1.3. Хезмәт күрсәтү срогы ______ елның «____»__________ башлап _______ елның «____»__________ кадәр билгеләнә.

## 2. ХЕЗМӘТНЕҢ БӘЯСЕ

2.1. Әлеге Шартнамә буенча хезмәт бәясе (Шартнамә бәясе) ________________________ (_____________________________________________________________) сум тәшкил итә.

2.2. Шартнамә буенча хезмәтләргә түләү Заказчы тарафыннан 100% алдан түләп кую шартларында башкарыла.

2.3. Әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәт бәясен түләү Заказчы тарафыннан налсыз тәртиптә Башкаручы счет чыгарган көннән башлап 3 (өч) календарь көне эчендә акча чараларын әлеге Шартнамәнең 9 нчы бүлегендә күрсәтелгән реквизитлар буенча Башкаручының исәп-хисап счетына күчерү юлы белән яисә мөрәҗәгать иткән көнне Башкаручы кассасына акчалата түләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.4. Заказчының түләү буенча йөкләмәләре үтәлгән булып санала:

2.4.1. әгәр Заказчы юридик зат булып торса – акча чаралары Башкаручының ФКИдәге исәп-хисап счетына күчкән яки Башкаручы кассасына килгән датага.

2.4.2. әгәр Заказчы булып физик зат торса:

налсыз исәп-хисап ясау формаларыннан файдаланганда – акча чаралары Башкаручының ФКИдәге исәп-хисап счетына күчкән датага.

акчалата исәп-хисап ясау формаларын файдаланганда – акчаларны Башкаручыга яисә кредит оешмасына, яисә физик затлардан түләүләр кабул итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы түләү агентына, яки банклар һәм банк эшчәнлеге турында законнар нигезендә эшчәнлек башкаручы банк түләү агентына (субагентка) керткән вакыттан башлап.

2.5. Башкаручы әлеге Шартнамәнең 1.1. п. күрсәтелгән хезмәткә әлеге Шартнамә нигезендә Заказчы тарафыннан түләнгәч (түләгәнлекне раслый торган документлар булганда) әлеге Шартнамә кысаларында үзенең вазыйфаларын үтәргә керешә.

## 3. БАШКАРУЧЫНЫҢ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

3.1. Башкаручы түбәндәгеләрне бурычы була:

3.1.1. хезмәтне әлеге Шартнамәгә туры китерелгән күләмдә һәм срокларда гамәлгә ашырырга;

3.1.2. документларда булган персональ белешмәләрнең яклануын тәэмин итәргә;

3.1.3. әлеге Шартнамәнең 1.1. п. күрсәтелгән хезмәтне тиешле сыйфатта күрсәтергә.

## 4. ЗАКАЗЧЫНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Заказчы түбәндәгеләрне бурычлы була:

4.1.1. әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны, шул исәптән персональ белешмәләрне һәм хезмәткә түләнгәнлекне раслаучы документларны Башкаручыга тапшырырга;

4.1.2. Башкаручының әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәте өчен әлеге Шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда вакытында түләргә;

4.1.3. хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча Башкаручы тарафыннан әзерләнгән документларны кабул итәргә.

## 5. ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ТУРЫНДА ДОКУМЕНТЛАРНЫ РӘСМИЛӘШТЕРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтне күрсәтү тәмамлангач, Башкаручы ике нөсхәдә Хезмәт күрсәтү турында акт төзи һәм Заказчыга тапшыра, аның формасы әлеге Шартнамәгә 1 нче кушымтада билгеләнде.

5.2. Заказчы Хезмәт күрсәтү турында актка әлеге Шартнамәнең 1.1 п. аталган хезмәт күрсәтелгән көнне кул куя.

Заказчы Башкаручы тарафыннан әлеге Шартнамәнең 3 нче бүлегендә күрсәтелгән шартлар

үтәлмәгән очракта Хезмәтләр күрсәтү турында актка кул куюдан баш тартырга хокуклы.

5.3. Дәүләти һәм муниципаль хезмәт алуга гаризаны һәм теркәлгән документларны, шул исәптән әлеге Шартнамәнең 1.1 п. нигезендә төзелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча хакимият органы тарафыннан теләсә нинди карар кабул ителгән очракта хезмәт күрсәтелгән дип санала.

## 6. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

6.1. Заказчы һәм Башкаручы әлеге Шартнамәне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

6.2. Башкаручы тарафыннан әлеге Шартнамәнең 1.1 п. аталган хезмәт күрсәтелгәннән соң Заказчы Башкаручы хезмәтләреннән баш тарткан очракта, хезмәтләрнең Заказчы тарафыннан түләнгән бәясе кайтарып бирелми, бу хакта вазыйфаи затлар тарафыннан тиешле беркетмә төзелә, аның формасы әлеге Шартнамәгә 2 нче кушымтада билгеләнде.

6.3. Заказчы Башкаручы хезмәтләреннән баш тарткан очракта яки әгәр Заказчы әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документларны (документны) Башкаручыга бирмәсә (тапшырмаса), әлеге Шартнамәнең 1.1 п. аталган хезмәтне күрсәтә башлаганчы Заказчы тарафыннан хезмәтләрнең түләнгән бәясе Заказчыга кайтарып бирелә.

Түләүне кайтарып бирү Заказчының түләүне кайтару турында гаризасы яки суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.4. Әгәр хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, Заказчы тарафыннан тапшырылган мәгълүмат һәм документлар гамәлдәге законнарның таләпләренә җавап бирмәсә, Башкаручы хезмәтне күрсәтү нәтиҗәсе өчен җаваплы булмый.

6.5. Форс-мажор хәлләре барлыкка килгән очракта (һава торышы, гадәттән тыш яки хәрби хәл кертелү һ.б.), Башкаручы тарафыннан хезмәтләр күрсәтү гамәлдән чыгарыла. Бу вакытта хезмәт күрсәткән өчен түләү Заказчыга кайтарып бирелә.

## 7. КОНФИДЕНЦИАЛЬЛЕК ТУРЫНДА ШАРТЛАР

7.1. Хуҗалык-коммерция эшчәнлегенә, техник мөмкинлекләргә яки Якларның финанс хәленә кагыла торган теләсә нинди мәгълүмат конфиденциаль һәм Яклар тарафыннан таратырга ярамый торган мәгълүмат булып санала. Яклар әлеге Шартнамәне үтәү барышында алынган мәгълүматның катгый конфиденциаль булуын сакларга сүз бирә, бер-берсе турындагы конфиденциаль холыклы белешмәләрне таратмаска, шулай ук әлеге Шартнамәне үтәү барышында алынган мәгълүматны бер-берсенә зыян китерерү өчен файдаланмаска сүз бирә. Конфиденциаль мәгълүмат өченче затларга бары тик икенче Як ризалыгы белән генә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә аны таләп итү хокукына ия булган дәүләт органнарына мәгълүмат тапшырылган очракта гына бирелергә мөмкин.

## 8. БАШКА ШАРТЛАР

8.1. Шартнамә кул куелган вакыттан башлап үз көченә керә һәм якларның үз өсләренә алынган барлык вазыйфалары үтәлгәнчегә кадәр гамәлдә була.

8.2. Шартнамәдә җайга салынмаган барлык мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге нормалары кулланыла.

8.3. Шартнамәне төзегәндә, башкарганда, үзгәрткәндә, өстәмәләр керткәндә яки таркатканда барлыкка килә торган бәхәсле мәсьәләләрне Яклар сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл итәчәк. Ризалыкка ирешелмәгән очракта бәхәсләр Татарстан Республикасы Арбитраж судында (әгәр Заказчы физик зат булса – җаваплы як урнашкан урын буенча гомуми юрисдикция судында) дәгъва белдерү юлы белән бәхәсне судка кадәрге тәртиптә җайга салганнан соң каралачак. Дәгъваны карау срогы аны алган вакыттан башлап 10 көн тәшкил итә.

8.4. Әлеге Шартнамә ике, һәр якка берәр нөсхәдә төзелде.

8.5. Әлеге Шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр язмача рәвештә рәсмиләштерелгән, ике Як тарафыннан имзаланган булсалар, гамәлдә булып санала.

8.6. Әлеге Шартнамәгә Яклар тарафыннан килештерелгән һәм рәсмиләштерелгән өстәмәләр һәм кушымталар аның аерылгысыз өлеше булып тора.

8.7. Якларның үзара ризалыгы нигезендә Шартнамә таркатылырга мөмкин.

8.8. Түбәндәге кушымталар әлеге Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора:

8.8.1. Күрсәтелгән хезмәтләр турында акт формасы (1 нче кушымта);

8.8.2. әлеге Шартнамә шартларын бозу турында беркетмә формасы (2 нче кушымта).

## 9. ЯКЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| Башкаручы: | Заказчы: |
|---|---|
| «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе | ______________________________ |
| Юридик һәм почта адресы:<br>420054, Казан ш., Авангард урамы, 74<br>Тел/факс: 222-06-20<br>e-mail: mfc-kazan@yandex.ru | ______________________________ |
| Банк реквизитлары: | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| /____________/____________________/<br>(имза) (Ф.И.А.) | /____________/ ____________________/<br>(имза) (Ф.И.А.) |

м.у.

________________ № _____
шартнамәгә 1 нче кушымта

**РӘВЕШЕ**

## Күрсәтелгән хезмәтләр турында акт

___________________ ш. «___» ____________ _____ ел.

«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе,_________________________ _________________________________________________ исеменнән, «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе филиалы турында нигезләмә, «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе Уставы нигезендә гамәл кылучы, алга таба «Башкаручы» дип атала, бер яктан, һәм_______________________________ ____________________________________________________________________________,
(гражданинның Ф.И.А., оешманың аталышы)
алга таба «Заказчы» дип атала, икенче яктан (алга таба – Яклар) әлеге Акты төзеде, түбәндәгеләр хакында:

1. Хезмәтләр күрсәтү турында __________________ № _____ шартнамә нигезендә Башкаручы тулысынча түләү шартларында хезмәтләрнең бөтен комплексын башкарды, ә атап әйткәндә_____________________________________

_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________

2. Югарыда аталган хезмәтләр Шартнамә нигезендә _____ елның «__»__________ башкарылды. Хезмәтләрне күрсәтү урыны ___________________________________ ________________________________________________.

3. Түләү Заказчы тарафыннан ____ елның «___» _________ башкарылды.

4. Күрсәтелгән хезмәтләрнең нәтиҗәсен кабул иткәндә билгеләнгәнчә, хезмәтләр тулы күләмендә үтәлгән.

5. Хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләре буенча Заказчыда ризасызлыклар юк.

6. Шартнамәдән күрсәтелгән хезмәтнең нәтиҗәсен начарлатырлык чигенешләр яки эштә бүтән җитешсезлекләр ачыкланмады.

Заказчы_________________________________ «___» ___________ _____ ел.
(имза, Ф.И.А.)

Башкаручы /_______________/ _______________ «___» ___________ _____ ел.
(имза) (Ф.И.А.)

_______________ № _____
шартнамәгә 2 нче кушымта

Формасы

Документлар төзү буенча хезмәтләр күрсәтү турында
шартнамә шартларын бозу турында беркетмә

__________________ ш. «___» ____________ _____ ел.

Урынга чыккан төркем, түбәндәгеләр составында:

_______________________________________________________________________________,
(беркетмә төзегән затның Ф.И.А., вазыйфасы)

_______________________________________________________________________________,
(беркетмә төзегән затның Ф.И.А., вазыйфасы)

_______________________________________________________________________________,
(беркетмә төзегән затның Ф.И.А., вазыйфасы)

әлеге беркетмәне төзеде, түбәндәгеләр хакында:

1. Документларны төзү буенча хезмәтләр күрсәтү турында __________ № _____ шартнамә нигезендә «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Башкаручы) ____________________________________________________________ өчен хезмәтләрнең бөтен
(юридик затның аталышы, физик затның Ф.И.А.)
Комплексын тулысынча түләү шартларында үтәде, ә атап әйткәндә_______________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

2. Югарыда аталган хезмәтләр шартнамә нигезендә ________ елның «____» ___________ үтәлде. Хезмәтләрне күрсәтү урыны _______________________________________________
______________________________________________________________.

3. Түләү Заказчы тарафыннан ____ елның «___» _________ башкарылды.

4. Хезмәтләр күрсәтү турында ____________ № ___________ шартнамә шартларын һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирү өчен «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчегә аның гарызнамәсе нигезендә урынга чыгып хезмәтләр күрсәтү буенча нигезләмә раслау турында» ______________ № _______ боерыгын бозып, Заказчы хезмәтләр Башкаручы тарафыннан күрсәтелгәннән соң Башкаручы хезмәтләреннән баш тартты
_______________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

Заказчы__________________________________________ «___» ___________ 2____ ел. *

Башкаручы вәкилләре: ______________________________ «___» ___________ 2____ ел.
______________________________ «___» ___________ 2____ ел.
______________________________ «___» ___________ 2____ ел.

** Заказчы беркетмәгә кул куюдан яки беркетмә Заказчы юклыгында төзелгән очракта, беркетмәдә тиешле тамга ясала.*

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының _______ № _____ боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 2 нче кушымта

**ФОРМАСЫ**

**Түләүле хезмәтләр күрсәтү турында хисап**

______________________________________________

(бүлекнең яки филиалның аталышы)

**«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе**

| № п/п | Түләүле хезмәтнең исеме | Күрсәтелгән хезмәтләр саны, бер. | | Суммасы, сум | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | хисап датасына үсә баручы нәтиҗәсе белән | шул исәптән хисап чорының соңгы ае өчен | хисап датасына үсә баручы нәтиҗәсе белән | шул исәптән хисап чорының соңгы ае өчен |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
____________________
№ _____ боерыгы белән
расланды

**«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирү өчен «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә аның гарызнамәсе нигезендә урынга чыгып хезмәтләр күрсәтү буенча нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Граждан колексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар һәм юридик затлар өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы карамагында торган дәүләт бюджет учреждениеләренең төп эшчәнлек төрләренә карый торган хезмәтләрне күрсәткән (эшләрне башкарган) өчен түләү билгеләүнең үрнәк тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы карары, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе Уставы (алга таба – Устав) нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр:

урынга чыгып хезмәт күрсәтү (алга таба – Хезмәт күрсәтү) – дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү һәм тиешле язу/исемлек теркәп, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү урынына документларны китерү максатында «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Учреждение) белгеченең аның гарызнамәсе буенча заказчы (мөрәҗәгать итүче) янына баруы һәм (яки) тиешле язу/исемлек төзеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән документларны китерү максатында Учреждение белгеченең заказчы гарызнамәсе буенча аның янына баруы;

заказчы (мөрәҗәгать итүче) – Хезмәт күрсәтү артыннан мөрәҗәгать иткән, шәхсән яки Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә гамәл кылучы вәкаләтле вәкиле аша эш итүче физик зат яки юридик зат;

заказчы вәкиле – заказчы мәнфәгатьләрендә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән, үзенең вәкаләтләрен раслаучы документ нигезендә эш итүче зат;

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү урыны – Учреждение бүлекләре һәм филиаллары;

башкаручы – тиешенчә бүлек яки филиал турында Нигезләмә нигезендә гамәл кылучы Учреждение бүлеге яки филиалы;

хакимият органы – Учреждение белән төзелгән хезмәттәшлек итү турындагы килешүләр нигезендә Учреждение бүлекләрендә яки филиалларында хезмәтләре күрсәтелә торган федераль башкарма хакимият органының территориаль органы, бюджетныкы булмаган дәүләт фондының территориаль органы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы.

1.3. Әлеге Нигезләмә Хезмәтләр күрсәтелгәндә заказчы белән башкаручы арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1.4. Нигезләмәдә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын һәм файдалану мөмкинлеген арттыру максатында заказчыларга Хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

1.5. Хезмәтләрне күрсәтү башкаручының төп эшчәнлегенә зыян салырга яки аның сыйфатын начарайтырга тиеш түгел.

1.6. Башкаручы дәүләти, муниципаль һәм Учреждение боерыгында расланган исемлеккә кертелгән бүтән хезмәтләрне күрсәтү максатларында заказчыларга урынга чыгып хезмәт күрсәтү буенча Хезмәтләр күрсәтә.

## 2. Хезмәтләрне күрсәтү тәртибе

2.1. Учреждение «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – Интернет), шул исәптән Учреждениенең рәсми сайтында, Учреждение бүлекләрендә һәм филиалларында мәгълүмат стендларында Хезмәтләр күрсәтү турында мәгълүмат урнаштыра:

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада китерелгән үрнәк формага туры китереп, урынга чыгып хезмәт күрсәтү турында шартнамә (алга таба – Шартнамә) формасын;

урынга чыгып күрсәтелә торган дәүләти, муниципаль һәм бүтән төрле хезмәтләр исемлеген;

күрсәтелә торган Хезмәтләрнең шартларын (шул исәптән Хезмәтләрне күрсәтү тәртибен һәм бәясен, урынга чыгып хезмәт күрсәтү графигын);

Хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен җаваплы затларның элемтә өчен телефон номерларын, фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен (соңгысы булган очракта);

Хезмәтләрне күрсәтү территорияләренең исемлеген;

Хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә корреспонденция кабул итү адресларын (шул исәптән телефон номерын һәм электрон почта адресларын).

Шартнамә гавами оферта булып тормый һәм аңа карата Россия Федерациясе Граждан кодексының 437 ст. нигезләмәләре кулланылмый.

2.2. Учреждение боерыгы белән түбәндәгеләр билгеләнә:

урынга чыгып күрсәтелә торган дәүләти, муниципаль һәм бүтән төрле хезмәтләр исемлеге;

Хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен җаваплы вазыйфаи зат;

заказларны теркәүгә алу журналының формасы һәм аны тутыру тәртибе;

Хезмәтләр күрсәтүгә язылуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге;

кабул ителгән документларны эшкәртү Хезмәтен күрсәтүне тикшерүдә тотучы вазыйфаи затлар исемлеге;

Хезмәтләрне күрсәтү графигы һәм территорияләре исемлеге;

турыдан-туры урынга чыгып хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар урнашачак торак пунктлары исемлеге.

2.3. Хезмәтләр күрсәтүгә язылу гамәлгә ашырыла торган вазыйфаи зат тарафыннан заявкаларны теркәүгә алу журналы алып барыла, анда заказчының (әгәр заказчы физик зат булса) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта) яки юридик затның аталышы (әгәр заказчы булып юридик зат торса), элемтә телефоннары, Хезмәтләр күрсәтеләчәк урынның төгәл адресы, урынга чыгып хезмәт күрсәтү кысаларында заказчы алырга теләгән дәүләти һәм муниципаль хезмәтнең исеме, Хезмәтләрне күрсәтүнең килешенгән датасы һәм вакыты күрсәтелә. Хезмәт күрсәтү кысаларында Заказчылар янына чыгу Учреждение боерыгында расланган графикка туры китереп башкарыла.

Хезмәтләр күрсәтүгә язылуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат заказны эшкәрткәндә заказчы белән элемтәгә керә һәм Хезмәтләр күрсәтүнең урынын һәм вакытын тәгаенләштерә.

2.4. Хезмәт Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәренең мөрәҗәгать итүче янына барганы өчен түләү исәпләү тәртибе һәм Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәренең мөрәҗәгать итүче янына аның гарызнамәсе нигезендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүен, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирүен оештыру түләүсез гамәлгә ашырыла торган Гражданнар категорияләре исемлеген билгеләү турында» 2017 елның 07 декабрендәге 945 номерлы карары белән билгеләнгән исемлектәге затлар категорияләре өчен генә, раслаучы документларны күрсәткән очракта, түләүсез гамәлгә ашырыла. Хезмәт бары тик үз мәнфәгатьләрең өчен генә күрсәтелә.

Гражданнарның бүтән категорияләре өчен Хезмәт түләү нигезендә күрсәтелә. Түләү заказчы тарафыннан налсыз акча түләү юлы белән шартнамәгә кушымтада күрсәтелгән реквизитлар буенча башкаручының исәп-хисап счетына яки Хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы белгечкә акчалата түләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү күләме Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп, Учреждение борыгы нигезендә раслана.

2.5. Хезмәтләрне күрсәтү нигезе булып Хезмәтләрне түләүсез/түләүле күрсәтү турында хезмәтләр күрсәтүнең бәясен, срокларын һәм тәртибен билгеләгән шартнамә (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтага туры китерелгән формада) һәм түләгәнлекне раслый торган документ тора. Шартнамә яклар тарафыннан Хезмәтләр күрсәтелер алдыннан ике нөсхәдә яклар тарафыннан имзалау юлы белән төзелә. Шартнамәнең бер нөсхәсе заказчыда, икенчесе Учреждениедә саклана. Хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә Учреждение исеменнән Учреждение директоры яки аның тарафтан вәкаләт бирелгән зат тарафыннан имзалана.

2.6. Хезмәтләр күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчеләргә хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә хезмәт күрсәтүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актында расланган Стандарты, Учреждение бүлекләрендә һәм филиалларында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Учреждение боерыгында расланган Регламенты нигезендә Шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла. Хезмәтне күрсәтү факты Хезмәтләр күрсәтү турында актта (урынга чыгып хезмәт күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк формасына кушымтада китерелгән форма буенча), тапшырылган документларның исемлеген/язуын төзеп, шулай ук урынга чыгуларны теркәү журналында теркәлә. Тапшырылган документлар исемлегендә/язуында Хезмәтне күрсәтү датасы һәм урыны, тапшырылган документларның аталышы һәм комплектлылыгы күрсәтелә.

2.7. Шартнамә буенча бары тик тиешле документлар пакетында мөрәҗәгать итүче буларак күрсәтелгән, шартнамә нигезендә аның артыннан урынга чыгу (аны) (китерү) гамәлгә ашырыла торган бер генә зат заказчы (шул исәптән мөрәҗәгать итүченең тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән, үзенең вәкаләтләрен раслый торган документ нигезендә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш йөртүче вәкиле) була ала.

2.8. Әгәр башкаручының вазыйфаи заты Хезмәт күрсәтүнең заказчы тарафыннан күрсәтелгән урынына килгәннән соң 30 минут эчендә заказчы башкаручының вазыйфаи затына эш шартларын (220В көчәнешле электр челтәрләреннән файдалану, кирәкле мебель: өстәл, урындык) тәэмин итмәсә яки заказчы башкаручыга документларны тапшыруга (башкаручыдан кабул итеп алырга) әзер булмаса, Хезмәт күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк формасына кушымтада китерелгән форма буенча беркетмә төзеп, Хезмәт күрсәтелми.

2.9. Хакимият органы тарафыннан законнардагы таләпләргә туры китереп теләсә нинди карар кабул ителгән очракта, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү йомгаклары буенча документлар заказчыга җиткерелү шарты белән, шул исәптән, әгәр башкаручының вазыйфаи затлары билгеләнгән вакытта заказчы күрсәткән адрес буенча килсә, ләкин заказчы документларны тапшырудан баш тартса яисә читләшсә, бу хакта башкаручының вазыйфаи затлары урында Хезмәт

күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк формасына кушымтада китерелгән форма буенча беркетмә төзи, – Хезмәт тиешле рәвештә күрсәтелгән булып санала.

2.10. Хезмәтләрне күрсәтү якланган элемтә каналлары аша модемнан интернетка чыгып, мобиль персональ компьютердан файдаланып, портатив принтердан, сканердан яки фотоаппараттан файдаланып гамәлгә ашырыла, әгәр аталган техник чараларны куллану урынга чыгып хезмәт күрсәтү кысаларында күрсәтелә торган дәүләти, муниципаль хезмәтне күрсәтү тәртибен җайга салучы норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү өчен зарури булса.

2.11. Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү йомгаклары буенча әзерләнгән документларны китереп бирү Заказчы белән китереп бирүнең датасын, вакытын һәм урынын алдан килештереп, тиешле язуны/исемлекне төзеп гамәлгә ашырыла, ләкин күрсәтелгән дәүләти һәм муниципаль хезмәт буенча документларны әзерләү һәм таныклау көненнән соң килүче бер эш көненнән дә иртәрәк түгел.

2.12. Әгәр Учреждение белән хакимият органы арасында төзелгән Үзара хезмәттәшлек турында килешүдә хезмәт нәтиҗәсен Учреждение бүлегендә яки филиалында алу каралмаган булса, дәүләти яки муниципаль хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документларны Заказчыга китереп бирү хезмәтләре Шартнамәгә кертелми, ә Заказчы (шул исәптән Заказчының тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән, үзенең вәкаләтләрен раслый торган документ нигезендә гамәл кылучы вәкиле) хезмәт нәтиҗәсен Хакимият органыннан мөстәкыйль килеп ала.

## 3. Җаваплылык

3.1. Хезмәтләрне күрсәткәндә Башкаручы түбәндәгеләр өчен җаваплы була:

- дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итеп алудан баш тарткан өчен;
- заказчыдан законнарда каралмаган документларны таләп иткән өчен;
- документларны кабул итү срокларын һәм тәртибен саклаган, исәпкә алу кенәгәсенә язулар теркәүнең, документларны кабул иткәндә исемлекне/язуны рәсмиләштерүнең дөреслеге өчен, теркәлгән гарызнамәнең/гаризаның күчермәсен теркәү номерын һәм аны кабул итү датасын күрсәтеп биргән өчен.

3.2. Башкаручы түбәндәгеләр өчен җаваплы түгел:

- заказчы тапшыра торган документларның тулы һәм дөрес булуы өчен;
- хакимият органы тарафыннан дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү сроклары бозылган өчен.

3.3. Заказчы түбәндәгеләр өчен җаваплы була:

- шартнамә буенча Хезмәтләр күрсәтү максатларында үз вакытында түләү буенча;
- тапшырыла торган документларның тулы һәм дөрес булуы өчен.

Татарстан Республикасы Икътисад министрының _____________ № _________ боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирү өчен «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә аның гарызнамәсе нигезендә урынга чыгып хезмәтләр күрсәтү буенча нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Үрнәк формасы**

**Урынга чыгып хезмәт күрсәтү турында**
**№ ____ шартнамә**

____________ ш. «___»____________ ______ел.

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирү өчен «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе, ______________________________________________________________ исеменнән, ______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
нигезендә эш йөртә, алга таба «Башкаручы» дип атала, бер яктан һәм ____________________________
______________________________________________________________________________
_____________________ исеменнән, _____________________________________________ нигезендә эш йөртә, алга таба «Заказчы» дип тала, икенче яктан, алга таба – Яклар дип аталалар, әлеге Шартнамәне төзеде, түбәндәгеләр хакында:

## 1. ШАРТНАМӘ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Заказчы йөкли, ә Башкаручы Заказчының беренчел заявкасы нигезендә үтәүнең түбәндәге төр территориясендә (V белән билгеләргә) хезмәт күрсәтү йөкләмәсен үз өстенә ала:

☑1.1.1. дәүләти яки муниципаль хезмәтләрне күрсәтү буенча тиешле язуны/исемлекне төзеп, гаризаны һәм документларны кабул итеп алу һәм китереп бирү өчен Заказчы янына урынга чыгып хезмәт күрсәтү:

-_____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________(тиешле Органның хезмәтләре күрсәтелә);

☐1.1.2. Заказчыдан кабул итү һәм дәүләти яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү урынына тиешле язуны/исемлекне төзеп, гаризаны һәм документларны китереп бирү буенча хезмәт күрсәтү (әлеге Шартнамәнең 1.1.1 пунктында күрсәтелгән хезмәтне күрсәтүгә бәйле документларны кабул итү буенча бер мәртәбә урынга чыгу гамәлгә ашырылганда):

-______________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________________

_____________________________________________(тиешле Органның хезмәтләре күрсәтелә);

☐1.1.3. әлеге Шартнамәнең ________ п. күрсәтелгән дәүләти яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү йомгаклары буенча әзерләнгән документларны китереп бирү буенча бер мәртәбә урынга чыгу/ике мәртәбә чыгу (кирәклесе астына сызарга), һәм тиешле язуны/исемлекне теркәп (әлеге хезмәтне күрсәткән өчен түләү күләме урынга чыгулар санына карый һәм һәр чыккан саен китереп бирелә торган документлар санына бәйле түгел);

1.2. Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү урыны – ______________________________

__________________________________________________________________________________________.

Әлеге Шартнамә максатлары өчен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү урыны булып «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең бүлеге, филиалы яки территориаль-аерымланган бүлекчәсе аңлашыла.

1.3. Үтәлү территориясе –_____________________________________________________.

Әлеге Шартнамә максатлары өчен үтәлү территориясе дигәндә аның чикләрендә Башкаручы әлеге Шартнамә буенча үзенең вазыйфаларын башкару йөкләмәсен алган территория аңлашыла.

1.4. Әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү өчен заявка формасы әлеге Шартнамәгә 1 нче кушымтада билгеләнде.

1.5. Хезмәтләрне күрсәтү срогы ____ елның «___» ________ башлап _____ елның «____» _________ кадәр билгеләнә.

## 2. ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ БӘЯСЕ ҺӘМ ИСӘП-ХИСАП ЯСАУ ТӘРТИБЕ

2.1. Әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләр Башкаручы боерыгында расланган түләү күләме нигезендә түләүсез/түләүле (кирәклесе астына сызарга) нигездә күрсәтелә.

Әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләр раслаучы документ күрсәтелгән очракта түләүсез күрсәтелә. Бу вакытта хезмәт бары тик үз мәнфәгатьләренең өчен генә күрсәтелә.

2.2. Әлеге Шартнамә суммасы ____________________ сум тәшкил итә.

(___________________________________________________________________________),

шул исәптән түбәндәге пунктларда күрсәтелгән хезмәтләр өчен:

1.1.1 – _______ сум;

1.1.2 – _______ сум;

1.1.3 – _______ сум.

2.3. Хезмәтләр өчен Заказчы тарафыннан түләнә (вариантларның берсен билгеләргә):

☐ әлеге Шартнамәнең 9 нчы бүлегендә күрсәтелгән реквизитлар буенча Башкаручының исәп-хисап счетына налсыз акча күчерү юлы белән;

☐әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү максатында Заказчы янына урынга чыгуны гамәлгә ашыручы Башкаручы вәкиленә акчалата түләү юлы белән.

2.4. Заказчы Башкаручыга аның фактта тотылган чыгымнарын каплау шарты белән, әлеге Шартнамәне үтәүдән баш тартырга хокуклы.

2.5. Хезмәтләр күрсәтү тәмамлангач Яклар тарафыннан Хезмәтләрне күрсәтү турында акт төзелә.

## 3. БАШКАРУЧЫНЫҢ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

3.1. Башкаручы түбәндәгеләрне бурычы була:

3.1.1. әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле документларны үтәү территориясендә торучы Заказчының урнашкан урыны буенча әлеге Шартнамәгә туры китерелгән күләмнәрдә һәм срокларда кабул итүне гамәлгә ашырырга;

3.1.2. документларда булган персональ белешмәләрнең яклануын тәэмин итәргә;

3.1.3. әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләрне һәм тиешле сыйфатта күрсәтергә һәм аларның уңайлылыгы өчен җавап бирергә.

## 4. ЗАКАЗЧЫНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Заказчы түбәндәгеләрне бурычлы була:

4.1.1. электрон почта ярдәмендә, шәхсән яки почта аша, документлар пакетының санын, күрсәтелә торган хезмәтнең төрен, 1.1 пунктта күрсәтелгән хезмәтнең үтәлү территориясе чикләрендә күрсәтеләчәк урын адресын күрсәтеп, Башкаручы адресына әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтүгә заявка җибәрүгә.

4.1.2. әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны Башкаручыга, шул исәптән әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү зарурлыгы турында гариза тутыру өчен персональ белешмәләрне тапшырырга;

4.1.3. әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны Башкаручыга тапшырырга;

4.1.4. хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләре буенча Башкаручы китереп биргән документларны кабул итәргә;

4.1.5. 1.11 п. күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү урынына Башкаручы хезмәткәрләре килгән вакытка аларның эше өчен шартлар тәэмин итәргә: бүлмә, җиһазларны (компьютер, принтер, сканер) эшләтү өчен кирәкле электр энергиясеннән файдалану мөмкинлеге, җайланмаларны урнаштыру һәм Башкаручы хезмәткәренә эшләү өчен кирәкле өстәл, Башкаручы хезмәткәрләре өчен урындыклар;

4.1.6. Башкаручы хезмәткәрләре хезмәт күрсәтү урынына килеп җиткән вакытка тапшырылырга тиешле документлар пакетының, гаризаларның/гарызнамәләрнең әлеге Шартнамәдә билгеләнгән күләме булуын тәэмин итәргә; әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән дәүләти, муниципаль яки бүтән хезмәтләр буенча мөрәҗәгать итүче булып торган затның (затларның) яки аның әлеге хезмәтләрне күрсәтү өчен мөрәҗәгать итәргә вәкаләтле вәкиленең катнашуын, әлеге затта (затларда) законнардагы таләпләргә җавап бирә торган, шәхес таныклаучы документларның һәм мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документларның булуын тәэмин итәргә.

4.1.7. Әлеге Шартнамәнең 2.2 һәм 2.3 п. нигезендә Хезмәт күрсәтү өчен түләргә.

## 5. ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТҮ ТУРЫНДА ДОКУМЕНТЛАРНЫ РӘСМИЛӘШТЕРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Әлеге Шартнамәнең 1.1 п. күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәмамлангач, Башкаручы ике нөсхәдә хезмәтләр күрсәтү турында акт төзи һәм Заказчыга тапшыра, аның формасы әлеге

Шартнамәгә 2 нче кушымтада билгеләнде.

5.2. Заказчы хезмәтләр күрсәтү турында актка хезмәтләр күрсәтелгән көнне актны Башкаручыдан алган вакыттан башлап кул куя.

Заказчы Башкаручы тарафыннан әлеге Шартнамәнең 3 нче бүлегендә күрсәтелгән шартлар үтәлмәгән очракта Хезмәтләр күрсәтү турында актка кул куюдан баш тартырга хокуклы.

5.3. Орган тарафыннан гамәлдәге законнарның таләпләре нигезендә теләсә нинди карар кабул ителүе очрагында хезмәт күрсәтелгән булып санала.

## 6. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

6.1. Заказчы һәм Башкаручы әлеге Шартнамәне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта (шул исәптән тапшырыла торган документларның тулы һәм дөрес булуы өчен) яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

6.2. Заказчы Башкаручы хезмәтләреннән баш тарткан очракта Заказчы тарафыннан хезмәтләр күрсәтү өчен Башкаручыга түләнгән акча суммасы, Башкаручының фактта тоткан чыгымнары өчен түләүне исәпкә алып, кайтарып бирелә, шулай ук әлеге Шартнамәнең 3 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча Беркетмә төзелә.

6.3. Башкаручы хезмәткәрләре Хезмәтләр күрсәтелү урынына килгәч әлеге Шартнамәнең 4.1.3 пунктын бозып Заказчы Башкаручы хезмәткәренә әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән дәүләти яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен кирәкле документларны бирмәсә (тапшырмаса), хезмәт күрсәтелгән булып санала, бу хакта урында вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Шартнамәнең 2 нче кушымтасында китерелгән формада тиешле Акт төзелә.

6.4. Башкаручы хезмәткәрләре Хезмәт күрсәтү урынына килгәч Заказчы Шартнамәдә билгеләнгән документларны алудан баш тартса яки читләшсә, хезмәтләр күрсәтелгән булып санала, бу хакта урында вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Шартнамәнең 2 нче кушымтасында китерелгән формада тиешле Акт төзелә.

6.5. Башкаручы хезмәткәре Хезмәтләр күрсәтү буенча Заказчы тарафыннан күрсәтелгән урынга килеп җиткәч 30 минут эчендә Заказчы Башкаручы хезмәткәренә эш шартларын (җайланмаларны эшләтү өчен кирәкле электр энергиясеннән файдалану мөмкинлеген, җайланмаларны урнаштыру һәм Башкаручы хезмәткәренең эше өчен кирәкле өстәл, Башкаручы хезмәткәре өчен урындык) тәэмин итмәсә яки Башкаручыдан документларны алуга (кабул итүгә) әзер булмаса, Хезмәт, әлеге Шартнамәгә 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча тиешле актны төзеп, күрсәтелми. Бу вакытта Башкаручының Шартнамә буенча йөкләмәләре үтәлгән, Хезмәт күрсәтелгән булып санала.

6.6. Әлеге Шартнамәнең 6.3, 6.4 һәм 6.5 пунктларында күрсәтелгән очракларда әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү өчен Заказчы тарафыннан Башкаручыга түләнгән акча суммасы Заказчыга кайтарылмый.

6.7. Әлеге Шартнамәнең 3.1 пунктын бозып, әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән хезмәтләр Заказчыга Башкаручы гаебе белән күрсәтелмәгән булса, әлеге хезмәтләрне күрсәтү өчен Заказчы тарафыннан Башкаручыга түләнгән акча суммасы Заказчыга кайтарып бирелә.

6.8. Заказчы гамәлдәге законнарның таләпләренә туры килми торган документлар пакетын тапшырган очракта, Хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсе өчен Башкаручы җаваплы булмый.

6.9. Форс-мажор хәлләре (һава торышы, гадәттән тыш яки хәрби хәл кертелү һ.б.) барлыкка килгән очракта Башкаручының Заказчы янына баруы гамәлдән чыгарыла, бу хакта әлеге Шартнамәнең 3 нче кушымтасында китерелгән формада тиешле беркетмә төзелә һәм килешү буенча хезмәтләр күрсәтүнең бүтән вакыты билгеләнә.

## 7. КОНФИДЕНЦИАЛЬЛЕК ТУРЫНДА ШАРТЛАР

7.1. Хуҗалык-коммерция эшчәнлегенә, техник мөмкинлекләргә яки Якларның финанс хәленә кагыла торган теләсә нинди мәгълүмат конфиденциаль һәм Яклар тарафыннан таратырга ярамый торган мәгълүмат булып санала. Яклар әлеге Шартнамәне үтәү барышында алынган мәгълүматның катгый конфиденциаль булуын сакларга сүз бирә, бер-берсе турындагы конфиденциаль холыклы белешмәләрне таратмаска, шулай ук әлеге Шартнамәне үтәү барышынла алынган мәгълүматны бер-берсенә зыян китереру өчен файдаланмаска сүз бирә. Конфиденциаль мәгълүмат өченче затларга бары тик икенче Як ризалыгы белән генә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә аны таләп итү хокукына ия булган дәүләт органнарына мәгълүмат тапшырылган очракта гына бирелергә мөмкин.

## 8. БАШКА ШАРТЛАР

8.1. Якларның ихтыярына һәм теләгенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән һәм, игълан ителгән яки фактик сугыш, гражданнар чуалышы, эпидемия, блокада, эмбарго, җир тетрәү, су басу, янгыннар һәм башка стихияле бәла-казалар һ.б. кертеп, алдан күреп булмый яки котылгысыз җиңеп булмый торган хәлләр белән аңлатылу сәбәпле Якларның берсе каршысында икенчесенең йөкләмәсен үти алмаганы өчен Якларның берсе дә җаваплы булмый.

8.2. Җиңеп булмаслык хәлләр йогынтысы нәтиҗәсендә үзенең йөкләмәләрен башкара алмаган Як икенче Якка булган каршылыклар һәм аларның әлеге Шартнамә буенча йөкләмәләр үтәлүенә йогынты ясавы турында хәбәр итәргә тиеш.

8.3. Яклар арасында яңа, Шартнамәдән килеп чыкмый торган шартларны барлыкка китерә торган теләсә нинди Килешенгәнлек Шартнамәгә өстәмә килешүләр формасында Яклар тарафыннан расланган булырга тиеш. Шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр алар язмача рәвештә рәсмиләштерелгән һәм Якларның тиешенчә вәкаләт бирелгән вәкилләре тарафыннан имзаланган булса, гамәлдә булып санала.

8.4. Шартнамә буенча үзенең хокукларын һәм йөкләмәләрен Яклар берсе икенче Якның язмача ризалыгын алдан алмыйча өченче затларга тапшырырга хокуклы түгел.

8.5. Шартнамә кул куелган вакыттан башлап үз көченә керә һәм якларның үз өсләренә алынган барлык вазыйфалары үтәлгәнчегә кадәр гамәлдә була. Башкаручының исәп-хисап счетына Заказчыдан акча чаралары күчкән вакыттан башлап хезмәтләр күрсәтелә башлый.

8.6. Шартнамәдә җайга салынмаган барлык мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге нормалары кулланыла.

8.7. Шартнамәне төзегәндә, башкарганда, үзгәрткәндә, өстәмәләр керткәндә яки таркатканда барлыкка килә торган бәхәсле мәсьәләләрне Яклар сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл итәчәк. Ризалыкка ирешелмәгән очракта, дәгъва белдерү юлы белән бәхәсне судка кадәрге тәртиптә җайга салганнан соң, бәхәсләр җаваплы як урнашкан урын буенча гомуми юрисдикция судында каралачак. Дәгъваны карау срогы аны алган вакыттан башлап 10 көн тәшкил итә.

8.8. Әлеге Шартнамә ике, һәр якка берәр нөсхәдә төзелде.

8.9. Әлеге Шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр алар язмача рәвештә рәсмиләштерелгән, ике Як тарафыннан имзаланган һәм Якларның түгәрәк устав мөһерләре белән беркетелгән булсалар, гамәлдә булып санала.

8.10. Әлеге Шартнамәгә Яклар тарафыннан килештерелгән һәм рәсмиләштерелгән өстәмәләр һәм кушымталар аның аерылгысыз өлеше булып тора.

8.11. Якларның үзара ризалыгы нигезендә Шартнамә таркатылырга мөмкин.

8.12. Түбәндәге кушымталар әлеге Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора:

8.12.1. хезмәтләр күрсәтүгә заявка (1 нче кушымта);

8.12.2. күрсәтелгән хезмәтләр турында акт формасы (2 нче кушымта);

8.12.3. Хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә шартларын бозу турында беркетмә формасы (3 нче кушымта).

## 9. ЯКЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| Башкаручы: | Заказчы: |
| --- | --- |
| «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе | ______________________________ |
| Юридик һәм почта адресы:<br>420054, Казан ш., Авангард урамы, 74<br>Тел/факс: 222-06-20<br>e-mail: mfc-kazan@yandex.ru | ______________________________ |
| Банк реквизитлары: | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| ______________________________ | ______________________________ |
| /______________/____________________/<br>(имза) (Ф.И.А.) | /______________/ ____________________/<br>(имза) (Ф.И.А.) |

__________________ № ______
шартнамәгә 1 нче кушымта

**Формасы**

**Мөрәҗәгать итүчеләр янына хезмәт күрсәтү урынына документларны китерү һәм күрсәтелгән хезмәт нәтиҗәләре буенча документларны китерү буенча хезмәтләр күрсәтү турында заявка**

| Хезмәтләргә заказ бирүче турында белешмәләр | |
|---|---|
| Физик затның ФИА яки юридик затның аталышы | |
| Мөрәҗәгать итүченең түләүсез хезмәт күрсәтү хокукына ия булган категориягә каравын раслаучы документ | |
| Урнашкан урын адресы | |
| Урынга чыгуларның кирәкле саны | |

| Хезмәтнең номеры | Урынга чыгып дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында күрсәтелә торган хезмәтнең аталышы | Пакетлар саны | Хезмәтләрне күрсәтү урынының адресы (башкару территориясе чикләрендә) | Өстәмә мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |

Башкаручы: Заказчы:

/_______________/_____________/ /_______________/_______________/

м.у.

________________ № _____
шартнамәгә 2 нче кушымта

**Формасы**

## Күрсәтелгән хезмәтләр турында акт

___________________ ш. «___» ____________ _____ ел.

«Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе, ____________________________ ______________________________ исеменнән, «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе филиалы турында нигезләмә, «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе Уставы нигезендә гамәл кылучы, алга таба «Башкаручы» дип атала, бер яктан, һәм_____________________________________________________________
(гражданинның Ф.И.А., оешманың аталышы)
алга таба «Заказчы» дип атала, икенче яктан (алга таба – Яклар) әлеге Акты төзеде, түбәндәгеләр хакында:

1. Хезмәтләр күрсәтү турында __________________ № _____ шартнамә нигезендә Башкаручы тулысынча түләү шартларында хезмәтләрнең бөтен комплексын башкарды, ә атап әйткәндә______________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

2. Югарыда аталган хезмәтләр Шартнамә нигезендә _____ елның «__»__________ башкарылды. Хезмәтләрне күрсәтү урыны____________________________________.
3. Түләү Заказчы тарафыннан ____ елның «___» _________ башкарылды.
4. Күрсәтелгән хезмәтләрнең нәтиҗәсен кабул иткәндә билгеләнгәнчә, хезмәтләр тулы күләмендә үтәлгән.
5. Хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләре буенча Заказчыда ризасызлыклар юк.
6. Шартнамәдән күрсәтелгән хезмәтнең нәтиҗәсен начарлатырлык чигенешләр яки эштә бүтән җитешсезлекләр ачыкланмады.

Заказчы_________________________________ «___» ___________ _____ ел.
(имза, Ф.И.А.)

Башкаручы /_______________/ _______________ «___» ___________ _____ ел.
(имза) (Ф.И.А.)

_________________ № _____
шартнамәгә 3 нче кушымта

Формасы

Урынга чыгып хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә шартларын бозу турында беркетмә

___________________ ш. «___» ____________ _____ ел.

Урынга чыккан төркем, түбәндәгеләр составында:

_______________________________________________________________________________________,
(беркетмә төзегән затның Ф.И.А., вазыйфасы)

_______________________________________________________________________________________,
(беркетмә төзегән затның Ф.И.А., вазыйфасы)

_______________________________________________________________________________________,
(беркетмә төзегән затның Ф.И.А., вазыйфасы)

әлеге беркетмәне төзеде, түбәндәгеләр хакында:

1. Документларны төзү буенча хезмәтләр күрсәтү турында __________ № _____ шартнамә нигезендә һәм _________ № _____ язу (исемлек) буенча «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Башкаручы) ____________________________________________________________________________________
(юридик затның аталышы, физик затның Ф.И.А.)

өчен хезмәтләрнең бөтен комплексын үтәде

түбәндәге шартларда (V тамгасы белән билгеләргә)

☐ _____ елның «___»________ Заказчы тарафыннан тулысынча түләү,

☐ хезмәтләрне түләүсез күрсәтү,

ә атап әйткәндә _____________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________.

2. Югарыда аталган хезмәтләр шартнамә нигезендә ________ елның «____» ___________ үтәлде. Хезмәтләрне күрсәтү урыны_____________________________________.

3. Хезмәтләр күрсәтү турында ____________ № ___________ шартнамә шартларын һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен китереп бирү өчен «Татарстан Республикасында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә аның гарызнамәсе нигезендә урынга чыгып хезмәтләр күрсәтү буенча нигезләмә раслау турында» ______________ № _______ боерыгын бозып, (V тамгасы белән билгеләргә):

☐ Заказчы Башкаручы вәкиле тарафыннан урынга чыгып хезмәт күрсәтелгәндә Башкаручы хезмәтләреннән баш тартты;

☐ Заказчы Башкаручы вәкиле тарафыннан урынга чыгып хезмәт күрсәтелгәнчегә кадәр Башкаручы хезмәтләреннән баш тартты;

☐ Түбәндәге шартлар барлыкка килү нәтиҗәсендә Хезмәт күрсәтелмәде:

_______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________.

Заказчы__________________________________________ «___» ___________ 2____ ел. *

Урынга чыгучы төркем:

______________________________ «___» ___________ 2____ ел.

______________________________ «___» ___________ 2____ ел.

______________________________ «___» ___________ 2____ ел.

** Заказчы беркетмәгә кул куюдан яки беркетмә Заказчы юклыгында төзелгән очракта, беркетмәдә тиешле тамга ясала.*